Дөньядагы телләр һәм аларны төркемләү. Төрки телләр. Башка телләр арасында татар теленең урыны. Татарлар яши торган төбәкләр.

**1.2 Тел һәм сөйләм**

Татар теленең төп тармаклары: фонетика. Лексикология. Сүз ясалышы, грамматика (морфология һәм синтаксис), орфография һәм пунктуация.

Сөйләм төрләре: телдән һәм язма сөйләм, кара-каршы сөйләшү (диалог) һәм монолог. Сөйләмнең төп берәмлекләре: сүз, җөмлә, текст.

**2. Фонетика. Орфоэпия. Графика. Аваз. Фонема.**

Татар телендә сузык һәм тартык авазларның үзгәрешләре. Сүзләргә транскрипция ясау. Басым. Интонация. Орфография турында төшенчә. Авазларның дөрес әйтелеше.

Сүзләргә фонетик анализ ясау.

Орфография турында төшенчә. Орфографик приниплар.

Бу өлкәләрдә эшләгән галимнәр һәм аларның төп хезмәтләре.

**3. Лексикология**

Лексика һәм лексикология. Сүзнең лексик мәгнәсе. Сүзнең күп мәгънәлелеге. Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр. Омоним, сининим, антоним сүзләр. Этимология турында төшенчә. Телдәге сүзләрнең килеп чыгышы, куллану өлкәсе һәм куллану ешлыгы буенча составы. Фразеологизмнар. Лексикография.

Бу өлкәдә эшләгән галимнәр һәм аларның төп хезмәтләре.

**4. Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы**

Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы буенча үтелгәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү:

- Сүзнең тамыры, нигезе һәм кушымчалар;
- Сүз ясалу ысуллары.

Татар һәм рус телләрендәге сүз төзелеше һәм сүз ясалышы үзенчәлекләре. Бу өлкәдә эшләгән галимнәр һәм аларның төп хезмәтләре. Сүзләрнең төзелешен һәм ясалышын тикшерү.

5. **10 нчы сыйныфта үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау**

**6. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү**

1. Укыган әсәргә яки караган спектакльгә бәяләмә язу
2. Сыйныф яки мәктәп тормышындагы берәр кызыклы вакыйга турында газетага мәкалә язу

3. Сыйныфташ дустыңа характеристика язу
4. Вакытлы матбугатта чыккан берәр мәкалә турында үз фикереңне белдереп, редакциягә хат язу
5. Милли сәнгатебезнең әһәмиятле казанышы турында сыйныфташлар алдында чыгыш ясау
6. Илдә һәм дөньяда бара торган сәяси вакыйгалар турында хәбәрдар булуыңны күрсәтү максатыннан, сыйныф каршында чыгыш ясау
7. Иҗади характердагы язма эшләр (изложение. сочинение) башкару
8. Төрле орфографик кагыйдәләргә карата диктантлар язу
9. Төрле эш кәгазьләре (гариза, автобиография, белешмә, беркетмә, килешү кәгазе һ.б.) язу
10. Фәнни-популяр стильдәге тестларны тәрҗемә итү

**11нче сыйныф**

**1. Грамматика**

Грамматика турында төшенчә. Грамматиканың бүлекләре, аларның өйрәнү объекты һәм үзара бәйләнеше турында гомуми мәгълүмат.

Татар теле грамматикасына нигез салган галимнәр, аларның төп хезмәтләре.

**2. Морфология**

Морфология буенча үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү; татар телендә сүз төркемнәре: исем, сыйфат, сан, рәвеш, алмашлык, фигыль, аваз ияртемнәре, хәбәрлек сүзләр; бәйлекләр, теркәгечләр; кисәкчәләр, ымлыклар, модаль сүзләр.

Сүзләргә морфологик анализ ясау.

**3. Синтаксис**

Синтаксис һәм пунктуация буенча үтелгәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү: сүз, сүзтезмә, җөмлә кисәкләре, җөмлә һәм текст;

- гади җөмлә синтаксисы: тезүле һәм ияртүле бәйләнеш, җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре, җөмләләрне төркемләү, сүз тәртибе;
- кушма җөмлә синтаксисы: тезмә һәм кушма җөмләләр һәм аларның төрләре.

Текст , туры һәм кыек сөйләм, уртак сөйләм үзенчәлекләре.

Татар телендә тыныш билгеләрен кую. Гади һәм кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясау.

**4. Стилистика һәм сөйләм культурасы**

Татар әдәби теленең функциональ стильләре.

**5. 10—11 нче сыйныфларда үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау.**

**6. Бәйләнешле сөйләм үстерү**

1. Фәнни стильдә доклад язарга өйрәнү.
2. Актуаль темага «түгәрәк өстәл янында» сөйләшү үткәрү.
3. Дәрестә язган берәр сочинениегә бергәләп анализ ясау.
4. Укытучылар көне уңаеннан укытучылардан һәм укучылардан интервью алу һәм аны, мәктәп стена газетасында бастыру өчен, текст буларак формалаштыру.
5. Конспектлар төзү, тезислар язу.
6. Күп телләрне өйрәнү мәсьәләләренә багышланган пресс-конференция уздыру.
7. Татарстанда икетеллелек мәсьәләләренә багышланган иҗади язма эшләр (сочинениеләр һәм изложениеләр) эшләү.
8. Төрле эш кәгазьләре (белдерү, беркетмә, акт һ. б.) язу.
9. Программада каралган әдәби әсәрләрне өйрәнгәннән соң, аларны анализлап һәм үз фикереңне белдереп, сочинениеләр язу.
10. Иҗтимагый-публицистик стильдәге текстларны тәрҗемә итү.

**Родная (татарская) литература**
**(татар төркемнәре)**

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**

**Укучылар үзләштерергә тиешле күнекмәләр:**

- матур әдәбиятның сәнгать төрләре арасындагы урынын, узенчәлекләрен билгеләү;
- татар матур әдәбиятының гомуми үсеш юлын, аның чорларын белү, ул чорларга хас үзенчәлекләрне күрергә өйрәнү;
- матур әдәбиятның халык тарихы, аның катлаулы борылышлары, аеруча хәлиткеч вакыйгалары белән аерылгысыз бәйләнгән булуын, аларның язучыларга ясаган тәэсирен күрсртеп бирү;
- классик язучыларнын әдәбият үсешендәге ролен аңлату;
- матур әдәбиятнң сәнгатьлелек ягыннан эволюциясен тоемлау;
- әдәбиятның үзләренә таныш гомуми мәсьәләләре, аерым язучылар иҗаты, аларның дәрестә үтелгән яки мөстәкыйль өйрәнелгән әсәрләре турында инша, изложение, реферат кебек язма эшләрдә һәм телдән иреклe рәвештә үз карашларын бәян итү.

**Укучылар үзләштерергә тиешле мәгълүмат:**

- программада өйрәну ечен каралган әсәрләр, аларга карата тәкъдим ителгән хезмәтләр;
- өстәмә белем чыганакларыннан (әдәби әсәрләр, фәнни әдәбият, тәнкыйди хезмәтләр, Интернеттан алынган материаллар) әдәбиятның гомуми мәсьәләләре, аерым язучыларның иҗаты, тормыш юлы, шәхси кичергәннәренең иҗат иткән әсәрләрендә чагылышы турында;
- программада каралмаган, әмма теге яки бу чорның әдәби мохитен киңрәк аңларга ярдәм итүче кайбер башка язучыларның тормыш юллары һәм иҗатлары;
- татар һәм рус әдәбиятлары бәйләнешенә караган кайбер материаллар һәм хезмәтләр;
- хәзерге татар әдәбияты авторларының укучыларның узләрен кызыксындырган әсәрләре;
- хәзерге татар вакытлы матбугатында басылучы аерым әсәрләр һ. б.;
- хәзерге татар әдәбияты белән театр, музыка, кино кебек сәнгать төрләре арасындагы бәйләнешләр һ. б.

**Әдәби-теоретик төшенчәләр:**

- -халык авыз иҗаты һәм әдәбият
- -халык авыз иҗаты жанрларыннан бәет, дастан, риваять һәм легендалар.

Әдәбият теориясеннән:

- -хикәя, фантастик хикәя,очерк, повесть, нәсер;

§ автобиографик повесть;
§ шигырь һәм поэманың үзенчәлекләре;
§ комедия жанры;
§ мәсәл жанрының үзенчәлеге;
§ әдәби әсәрнең сюжетын, композиция үзенчәлекләрен белү;персонаж, лирик герой, уңай һәм тискәре образлар;

**Укучының шәхси үсеш-үзгәреше:**

- укучының мөстәкыйль фикерләве, гомумиләштереп нәтиҗә ясау сәләте үсү;
- матур әдәбиятта халык тарихы, милләт язмышы гәүдәләнешенә төшенү; кешелеклелек, горурлык, үз-үзен бәяләү үсү;
- укучыда мәктәпне тәмамлап чыкканнан сон да матур әдәбият укуга ихтыяҗ булу;
- әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен аңларлык зәвык формалашу.

Укучыларының әдәбияттан белем, осталык бәм кунекмәләрена гомуми таләпләр

**Татар халык иҗаты жанрларыннан:**

— әкиятләр, аларның төрләрен, геройларының төп сыйфатларын;
— язучылар язган әкиятләрнең үзенчәлекләрен;
— дөнья халыклары әкиятләрен аера белү;
— мәкальләр, табышмаклар һәм кешенең тапкырлыгын, зирәклеген билгеләүдә аларның ролен аңлау;
— җырлар һәм аларның төрләрен аера белү;

— бәетләр, аларда сурәтләнгән чынбарлык вакыйгаларын;
— риваятьләр һәм легендаларны, аларның жанр үзенчәлекләрен белү таләп ителә.

**Әдәбият теориясеннән:**

— хикәя, фантастик хикәя, очерк, повесть, нәсерне аера белү;
— автобиографик повестьны;
— шигырь һәм поэманың үзенчәлеген белү;
— комедия жанры хасиятләрен аңлатып бирү;
— мәсәл жанрының үзенчәлеген;
— әдәби әсәрнең сюжетын тотып ала белү;
— уңай герой, тискәре герой, лирик герой төшенчәләрен белү;
— әдәби әсәрләрдән сурәтләү чараларын таба белү сорала.

**Татар мәдәниятеннән:**

— татар халкының гаилә-көнкүреш, гореф-гадәт һәм йолаларын аңлата белү;
— милли орнаментларны аера белү;
— әдәбиятка бәйле рәвештә балет, опера, сынчы кебек терминнарны аңлата белү сорала.

**10 — 11 нче сыйныфларда:**

— халык авыз иҗаты һәм әдәбият;
— халык авыз иҗаты жанрларыннан бәет, дастан, риваятьләр турында мисаллар китереп, аларга аңлатма бирә белү;
— аларның текстларыннан өзекләр китереп, мәгънәсен ачыклап бирә белү;
— әдипләрнең тормыш юлы һәм иҗаты турында тулырак мәгълүмат бирә алу;
— татар әдәбияты тарихын чорларга бүлә алу;
— татар әдәбияты тарихы турында өстәмә мәгълүмат туплап, аңлатып бирә алу: әдәби әсәрләрнең сурәтләү чараларыннан метафора, эпитет, чагыштыру, җанландыру, гипербола, аллегория һ. б. белү һәм мисаллар белән дәлилли алу;
— әдәби төрләр һәм жанрлар;
— әдәби әсәрләрнең эчтәлеген һәм төзелешен (тема, идея, сюжет, композиция, образлар системасы һ. б.) анализлый белү;
— матур әдәбияттагы мәңгелек темалар, әдәбиятның башка сәнгать төрләре белән бәйләнеше.

**Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:**

— текстның исеме, андагы таныш сүзләр ярдәмендә укучыларның эчтәлекне аңлаулары;
— укылган текст буенча әңгәмәдә катнаша алу, сөйләмдә гади һәм җәенке җөмләләрдән файдалана алу;
— өйрәнелгән язучылар турында сөйләп бирү;
— укылган текстның эчтәлеген сөйли һәм нәтиҗә ясый белү, аңа үз мөнәсәбәтеңне белдерә алу;
— тәкъдим ителгән ситуация, тема яки рәсем буенча 12—14 җөмләдән торган текст белән сөйли белү;
— уку һәм сөйләм барышында орфоэпик нормаларны саклау;
— балалар һәм үсмерләр өчен чыккан вакытлы матбугатны уку һәм файдалана алу.

## Укыту предметының эчтәлеге

## 10нчы сыйныф

Әсәрләрне уку һәм өйрәнү
Бәйләнешле сөйләм үстерү
Дәрестән тыш уку

**Татар әдәбияты тарихына кереш.** Әдәбиятның чорларга бүленеше. Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятына кыскача күзәтү.

Кол Гали. «Кыйссаи Йосыф» поэмасы. Аның сюжеты, төп образлар, автор күтәргән төп мәсьәләләр, әсәрнең үзеннән соңгы әдәбиятыбыз үсешенә ясаган тәэсире.

**Алтын Урда чоры тарихы**, мәдәниятенә кыскача күзәтү.

**Сәйф Сараи.** «Сөһәйл вә Бөлдерсен» дастаны. Әсәрдәге вакыйгаларның чынбарлыктагы нигезе, реальлеге, геройлар сурәтләнешенең үзенчәлекләре, мәхәббәт темасын күтәрүдә авторның шәркый традицияләргә таянуы.

«Идегәй» дастаны (өзек). Аның иҗат ителү тарихы, төп образларның бирелеше. Әсәрдә ил идарәсе, халык, дәүләт язмышы мәсьәләсе. Дастан турында төшенчә.

**Казан ханлыгы чоры әдәбияты** һәм мәдәнияте турында кыскача мәгълүмат.

Мөхәммәдьяр **иҗаты.** «Төхфәи мәрдан» поэмасы (өзекләр).

**XVII—XVIII йөз әдәбияты**на кыскача күзәтү.Мәүла Колый иҗаты.

XIX йөз әдәбиятына һәм мәдәниятенә күзәтү. Иҗтимагый-тарихи, мәдәни мохит, әдәби иҗаттагы төп юнәлешләр.

Габделҗәббар Кандалый. Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. «Иляһи, барча галәмне...» шигыре, «Сахибҗамал» поэмасы (өзек). Шагыйрьнең әдәбиятка алып килгән яңалыгы.

Шиһабеддин Мәрҗани. Тормышы һәм күпкырлы эшчәнлеге. Ш. Мәрҗани турында татар әдипләре. Мәрҗанинең татар иҗтимагый фикер үсешендәге роле.

Мифтахеддин Акмулла. Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. «Башка милләт алга таба барыр булды...», «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән» шигырьләре, «Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе» поэмасы (өзек).

Каюм Насыйри. Тормышы һәм күпкырлы эшчәнлеге. «Әбу-галисина кыйссасы» турында. Фантастик сурәтләү алымының сюжетны оештырудагы әһәмияте, гуманистик идеяләрнең яклануы, хаксызлыкка

I

каршы көрәш. Сатирик әсәрдә алымнар, ironияле сурәтләүләр К. Насыйри китапларыннан үрнәкләр.

Муса Акъегетзадә. Тормышы һәм иҗаты турында белешмә. «Хиса-меддин менла» повесте (өзек). Татар әдәбиятында җәдитчелек-кадим- челек мәсьәләсенең мәйданга чыгуы. Милләтнең бүгенгесе, киләчәге турындагы мәсьәләләрнең җитди куелышы. Әсәрдә искелек тарафдарларының тәнкыйтьләнүе, аларга алмашка килгән яңа кешеләрне күрсәтергә омтылыш, хатын-кыз язмышы мәсьәләсе.

Заһир Бигиев. Тормышы һәм иҗаты турында белешмә. «Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә» романы (өзек). Әсәрнең темасы, идеясе, образларның бирелеше, төзелеше. Роман жанры турында искә төшерү һәм белемне киңәйтү.

**XX йөз башы әдәбиятына күзәтү.**

Гаяз Исхакый. Әдип иҗатының яңалыгы. Татарча яшәү рәвешен башка мохиткә куеп карауда автор позициясе. «Ул әле өйләнмәгән иде» әсәре (өзекләр), анда катнаш гаилә мәсьәләсенең чагылышы. Холык, әхлакый нигез һәм кеше язмышы мәсьәләләренең үзара нык керешүе.

Габдулла Тукай. Шагыйрьнең XX гасыр башы татар әдәбияты үсешенә керткән өлеше. «Милли моңнар», «И каләм!» һәм «Сәрләүхә- сез», «Өзелгән өмид» шигырьләре. Шагыйрь һәм милләт язмышы мәсьәләсе. Әсәрләрнең темасы, идеясе. Тукай образының әдәбиятта, музыкада, сынлы сәнгатьтә чагылышы.

Композитор Нәҗип Җиһанов. Музыка сәнгате өлкәсендәге эш- чәнлеге турында белешмә. «Кырлай» симфоник поэмасын тыңлауга әзерләнүдә Г. Тукайның «Шүрәле» әсәре белән таныш булуның мөһимлеге.

Рәссам Бакый Урманче. Иҗаты турында белешмә. Тукай образын гәүдәләндергән әсәрләре.

Дәрдемәнд. Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. «Кораб», «Бәл- лү», «Видагъ», «Татар углы татармын» шигырьләре. Аларның темасы, идеясе.

Сәгыйть Рәмиев. Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. «Таң вакыты» һәм «Мин» шигырьләре. Авторның аларда үткәргән карашлары. Шагыйрь иҗатында гыйсъянчы герой.

Галиәсгар Камал. Иҗаты турында белешмә. «Бүләк өчен» комедиясе. Әсәрнең проблематикасы, көлкечел конфликт, образларның бирелеше.

Артист һәм язучы Габдулла Шамуков иҗаты. Аның татар театр сәнгатен үстерүдәге эшчәнлеге.

Фатих Әмирхан. Иҗаты турында белешмә. «Хәят» повесте (өзекләр). Әсәрнең идеясе, кеше психологиясен тасвирлауда авторның осталыгы.

Мирхәйдәр Фәйзи. Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. «Галиябану» драмасы. Әсәрдә мәхәббәт гүзәллеге һәм сафлыгы гәүдәләнеше, образлар бирелеше. Драманың җыр һәм музыка белән үрелгән беренче сәхнә әсәрләреннән берсе булу.

Шәехзадә Бабич. Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. «Исемнәр бакчасы», «Тукай үлгәч», «Язгы җыр» шигырьләре. Әсәрләрдә хатын-кызга мәхәббәтле караш, күренекле шәхесләребезне зурлау һәм яшәешебезнең илаһилык белән сугарылырга тиешлеге мәсьәләләренең алгы планга чыгуы. Шагыйрьнең күңел дөньясы чагылышы.

Ятлау өчен әсәсрләр

Габдулла Тукай. Милли моңнар.
Сәгыйть Рәмиев. Таң вакыты.
Дәрдемәнд. Кораб.
Фатих Әмирхан. Хәят (өзек).
Шәехзадә Бабич. Язгы җыр.

Әңгәмә кору өчен якынча темалар

Татар каһарманнары.
Мәгърифәт учаклары (мәшһүр татар мәдрәсәләре).
Тарих һәм сәнгать.
Минем яраткан героем.
Сәламәтлек һәм спорт.

Дәрестән тыш уку

Кол Гали. Кыйссаи Йосыф.
Гаяз Исхакый. Кәләпүшче кыз.
Фатих Әмирхан. Хәят.
Ибраһим Нуруллин. Тукай.

**11нче сыйныф**

Әсәрләрне уку һәм өйрәнү
Бәйләнешле сөйләм үстерү
Дәрестән тыш уку

**1917нче елдан соңгы әдәбият**

Революция тарафдарларының 1917 елның 7 ноябренә кадәр биргән вәгъдәләре: халыкка җир, ирек, тынычлык бирү, милли мәсьәләне гадел хәл итү. Ләкин боларның чынлыкта тормышка ашмавы. Яңа көч белән кабынган гражданнар сугышының авыр нәтиҗәләре. Әдәбиятта көрәш темасының үзәккә куелуы. Әдәбиятта аеруча характерлылары: «Ул кем?» (М. Гафури), «Каравылда» (М. Максуд), «Чәчәктән һәйкәл» (Ф. Бурнаш), «Декламацияләр» (Г. Камал) һ. б. Революцион көрәшнең бер гаилә кешеләрен аеруны сурәтләгән әсәрләр: «Канлы көннәрдә» (Ш. Усманов), «Яңа кешеләр» (Г. Ибраһимов).

**1920—1930нчы еллар әдәбиятына күзәтү**

Гражданнар сугышы, ачлык темаларының даими яктыртылуы. Яңа газеталар, журналлар чыгу. Аларның әдәби әсәрләрдә үткәрелергә тиешле идеологик якка нык тәэсире. Төрле әдәби төркемнәр барлыкка килү. Бер-беренә каршы килүче әдәби агымнарның (пролетар юнәлеш, футуризм, имажинизм һ. б.) яшәвенә әле мөмкинлек булу. Әдәбиятта аеруча еш

очрый торган темалар: кеше бәхете: «Мәхәббәт тәүбәсе» (Һ.Такташ),«Шобага», (К. Нәҗми), революциянең кеше язмышына ясаган тәэсире: «Яр буенда учаклар» (К.Нәҗми), «Эшче» (М.Гафури), «Бәхет» (М.Җәлил) һ.б. Яңа чынбарлыкны сурәтләүдә сәнгатьлелеккә игътибар арту: «Ил кызы», «Краском мәхәббәте» (Ш. Усманов). Татарстан һәм СССР язучыларының беренче съездлары (1934). Социалистик реализм иҗат методы, аның үзенчәлекләре. Әдәби иҗатка административлык алымнары белән тәэсир итү, моның нәтиҗәләре. «Агыйдел» (М. Әмир). Җәмгыятьтә әхлак нигезләрен аңлауда кискен борылыш. Гореф-гадәтләрнең күпчелеген санга сукмау, динне кире кагу. Күмәк хезмәтне данлау: «Кояшлы яңгыр» (К. Нәҗми). Шәхес культының җәмгыятькә һәм әдәбиятка китергән гаять зур зарары.

**Һади Такташ.** «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы.

**Гадел Кутуй.** «Тапшырылмаган хатлар» повесте. Әсәрдә мәхәббәт, гаилә, бәхет мәсьәләләренең бирелеше.

**1940—1950нче еллар әдәбиятына күзәтү**

Бөек Ватан сугышы алды һәм сугыш вакытында татар әдәбияты. Язучыларның сугышка корал һәм каләм белән катнашуы. Тылдагыларның фидакарь хезмәте һәм иҗаты. Иҗатта җиңүгә булган омтылышның үзәктә торуы. Сугыш һәм кеше, ил язмышы мәсьәләсенең барлык жанрлар өчен дә уртаклыгы. Шигърият, хикәянең активлашуы. Драма әсәрләре, аларның бу чордагы төп юнәлеше. М. Җәлил, Ф. Кәримнәрнең татар шигъриятен үстерүдәге рольләре. Т. Гыйззәт, М. Әмир, Н. Исәнбәт, Г. Кутуй, И. Гази, А. Шамов һ. б. әсәрләре. Илленче елларда да сугыш темасының дәвам иттерелүе. С. Хәким, Н. Арсланов, Г. Хуҗиев, Ф. Хөсни, А. Шамов, И. Гази һ. б. поэмалары, хикәяләре һәм повестьлары. М. Әмир, Р. Ишморатларның драма әсәрләре. Г. Әпсәләмов романнары. Г. Бәшировның «Намус» романы. Илленче еллар урталарында шәхес культының фаш ителүе. Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Ш. Усманов, Г. Толымбайский, Ф. С.-Казанлы, Ф.Бурнаш, И.Салахов, Л. Гыйльми һәм башкаларның исемнәре һәм әсәрләре кайту. Х. Туфанның намуслы исеме торгызылу, аның әдәбиятка кайтуының шигърият үсешендәге әһәмияте.

М. Җәлил исеменең һәм «Моабит дәфтәрләре»нең илгә кайтуы һәм моның җәмгыятькә һәм әдәбиятка китергән тәэсире. 1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрелү, аның әһәмияте.

**Муса Җәлил.** Шагыйрьнең сугышчан юлына, әсирлектәге тормышына һәм иҗатына күзәтү. “Моабит дәфтәрләре” циклына күзәтү. Андагы әсәрләрнең идея кыйммәте һәм сәнгатьлелек җәһәтеннән дөнья шгъриятенең иң югары казанышларыннан берсе булуы. Аерым әсәсрләренең әдәби эшләнешенә анализ. “Җырларым”, “Ышанма!”, “Тик булса иде ирек” шигырьләрендә батырлык пафосының бирелү үзенчәлекләре. Әдәбиятта. Музыкада, рәсем һәм сынлы сәнгатьтә Муса Җәлил образының бирелеше.

**Фатих Кәрим.** Тормыш юлы һәи иҗаты. “Сибәли дә сибәли” шигыре, “Разведчик язмалары” хикәясе. Ватанны ярату һәм аның азатлыгы өчен көрәшкә әзер тору, шагыйрьнең уйлары, халәте.

**1960нчы еллар һәм хәзерге чор әдәбиятына күзәтү**

Илдә илленче еллар урталарыннан соң булган кайбер уңай үзгәрешләрнең әдәбиятка тәэсире. Ә. Еники, А. Гыйләҗевларның тоталитар режимны тәнкыйтьләгән әсәрләре: «Саз чәчәге», «Рәшә» (Ә. Еники), «Өч аршын җир» (А. Гыйләҗев). Әкренләп тарихи теманың үзләштерелә башлавы: «Итил суы ака торур» (Н. Фәттах), «Кубрат хан», Атилла» (М. Хәбибуллин) һ. б. Михаил Худяков, Һади Атласи, Газиз Гобәйдуллин кебек галимнәрнең тарихи хезмәтләре кайтуның әдәбиятка тәэсире. Г. Исхакый исеменең һәм әдәби мирасының халыкка кайтуы, моның сүз сәнгатенә, тарихи фикерләүгә ясаган зур уңай тәэсире. СССРның таркалуы, әдәбиятта яңа темалар барлыкка килү.

**Поэзия**

**Хәсән Туфан.** Иҗатына күзәтү. «Ә үткәнгә хатлар бармыйлар» циклы, «Кармәт истәлекләре». Әсәрләрнең төп проблематикасы һәм безнең поэзиягә китергән яңалыгы. Х.Туфан һәм җыр сәнгате.

**Сибгат Хәким.** Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. «Гел кояшка карый тәрәзәләрең», «Башка берни дә кирәкми» шигырьләре. Әсәрләрдә туган якның сурәтләнеше, аларда нечкә лиризм.
**Гамил Афзал, Зөлфәт, Ренат Харис,** аларның үзенчәлекле яклары. Ренат Харис һәм композитор Р.Ахиярованың иҗади хезмәттәшлеге, «Шыгыйрь мәхәббәте” операсы.
**Равил Фәйзуллин.** Иҗаты турында белешмә. «Якты моң», «Яздан аерып булмый Тукайны!» шигырьләре. Аларда тирән уй, фәлсәфи олы фикернең бирелеше.
**Рәдиф Гаташ.** Иҗатына күзәтү. «Ирләр булыйк!», «Укытучы» шигырьләре. Әсәрләрдә күтәрелгән төп мәсьәләләр, аларның сәнгатьчә эшләнеше.
**Проза**
**Гомәр Бәширов.** Иҗаты турында белешмә. «Җидегән чишмә» романы *(өзек).* Әсәрдә табигатьне саклауның әһәмиятен ачу, геройларны бәяләүдә табигатькә мөнәсәбәтнең роле.
**Әмирхан Еники.** Иҗаты турында белешмә. «Әйтелмәгән васыять» әсәре *(өзек).* Язучының халык мирасына һәм ул мирасны бүгенгәчә саклап китереп җиткерүчеләргә хәзерге мөнәсәбәтне яктырту үзенчәлекләре.
**Мөхәммәт Мәһдиев.** Иҗаты турында белешмә. «Бәхилләшү» повесте *(өзек).* Әсәрдә авыл кешеләренең рухи дөньясын чагылдыру, аларның әхлакый сыйфатларының бирелеше.
**Нурихан Фәттах.** Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. «Итил суы ака торур» романы *(өзек).* Әсәрдә Бөек Болгар дәүләте төзелү, шул заман кешеләренең язмышы.
**Мәхмүт Хәсәнов** «Язгы аҗаган» әсәре (өзек). Бу әсәрләрдә җәмгыять һәм шәхес мөнәсәбәте проблемасының яңача хәл ителүе.
**Драматургия**
**Туфан Миңнуллин.** Иҗаты турында белешмә. «Үзебез сайлаган язмыш» пьесасы. Анда мәктәп тормышының һәм укытучылар образларының бирелеше, әхлак мәсәләләренең куелышы.
**Балалар әдәбияты**
Татар балалар әдәбиятына күзәтү. **Җәвад Тәрҗеманов, Хәкимҗан Халиков, Җәүдәт Дәрзаман**. Аларның әсәрләрендәге төп тема һәм проблемалар.
**Шәүкәт Галиев** иҗатына күзәтү. Аның шигырьләрендә кеше һәм шәхес буларак формалашу процессындагы катлаулы мөнәсәбәтләрнең чагылышы.
**Роберт Миңнуллин** иҗатына күзәтү. Аның балалар поэзиясен үстерүдәге эшчәнлеге. Шигырьләрдә темалар, образларның бирелеше.
**Ятлау өчен әсәрләр**
**Һ. Такташ.** Мәхәббәт тәүбәсе (өзек).
**М. Җәлил.** Ышанма!
**Ф. Кәрим.** Ант. Сөйләр сүзләр бик күп алар.
**С. Хәким.** Гел кояшка карый тәрәзәләрең.
**Р. Фәйзуллин.** Яздан аерып булмый Тукайны!
**Р. Гаташ.** Укытучыма. Ирләр булыйк.
**Әңгәмә кору өчен якынча темалар**
Туган як моңнары.
Күңелемдә мәңге калыр туган җирем.
Һөнәр сайлау
Яраткан язучым.
Яшел даруханә.
Батырлар даны мәңгелек
**Дәрестән тыш уку**
**Р. Мостафин.** Өзелгән җыр эзеннән.
**М. Хәсәнов.** Язгы аҗаган.
**М. Мәһдиев.** Торналар төшкән җирдә.
**Төп әдәби-теоретик төшенчәләр**

Әдәби төрләр һәм жанрлар. Образлар системасы. Шигырьтөзелеше. Автор образы, хикәяләүче образы, лирик герой. Әдәби әсәрдә сурәтләү чаралары. Татар әдәбиятында традицияләр һәм яңару процессы, жанрлар үсеше турында гомуми күзаллау булдыру.

**Родной (татарский) язык**
**(рус төркемнәре)**

**Укучылар үзләштерергә тиешле күнекмәләр:**

**Тыңлап аңлау**

· җанлы сөйләмне тыңлап аңлап, күмәк сөйләшүдә катнашу;
· тыңланган мәгЋлүматны аңлатып бирү.

**Диалогик сөйләм**

· аралашканда, төрле репликалардан (сораштыру, кабатлап сорау, тәкъдим итү, риза булу һ.6.) урынлы файдалану;
· әңгәмәдәшнең социалһ хәлен исәпкә алып, сөйләшү оештыру;
· аралашу барышында фикерне төгәл житкерү;
· киңәйтелгән репликалар кулланып, сөйләшү үткәрү;
· укылган текстларның эчтәлеге буенча бәхәсләрдә катнашу, үз ка- рашларыңны раслау һәм дәлилләү;
· укылган әдәби әсәрләрнең эчтәлеге буенча әңгәмә кору.

**Монологик сөйләм**

· Төрле җөмлә калыпларын урынлы кулланып, мөһим вакыйгалар, дөнһя яңалыклары турында хәбәр итү һәм аларга карата үз мөнәсәбәтеңне һәм фикерләреңне белдерү;
· сөйләм нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән бәйләнешле текст төзү, сөйләмне эзлекле һәм аңлаешлы итеп оештыру;
· татар классик әдипләренең тормышы Һәм иҗаты турында сөйләү;
· әдәби әсәрләрдә күтәрелгән проблемаларны аңлау Һәм үз фикерләреңне әйтү;
· әсәрдәге геройларны характерлап, алар турында фикер әйтү.

**Уку**

· уку төрләреннән файдаланып, тексттан кирәкле мәгълүматны табу Һәм аның эчтәлеген телдән яки язмача белдерү;
· текст белән мөстәкыйль эшләү кунекмәләренә ия булу;
· шигъри текстларны яттан сөйләү;
· автор позициясен, геройларның теге яки бу эш-гамәленә нигез булган мотивларны Һәм конфликтның асылын ачыклау;
· татар Һәм рус телләрендәге әдәби әсәрләрнең уртак Һәм милли үзенчәлекләрен билгеләү, әхлакый кыйммәтләрне чагыштырып бәяләү;
· татар әдәбияты классикларын Һәм аларның танылган әсәрләрен әйтеп бирү;
· аерым автор Һәм аның әсәрләре, татар әдәбияты турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, Интернет аша табу.

**Язу һәм язма сейләм**

· аралашу ситуациясенә карата фикерләрне язмача белдерү;
· өйрәнелгән темага яки укылган текстның эчтәлегенә нигезләнеп, сочинение язу;
· укылган яки тыңланган текстның планын төзеп, аның эчтәлеген язмача сөйләп бирү;
· тәкъдим ителгән темага реферат язу.

**Грамматик минимум.**

1. Татар сөйләмен фонетик яктан дөрес оештыру.
2. Татар телендә сүз басымының үзенчәлекләрен белү һәм аерым грамматик формалардагы сүзләрдә басымны дөрес кую
3. Сөйләмдә иҗек чигендәге фонетик үзгәрешләрне истә тоту
*4*. Хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләрне дөрес интонация белән әйтү.

5. Актив үзләштерелгән лексик берәмлекләрне, шул исәптән кушма, тезмә, парлы һәм кыскартылма сүзләрне, дөрес куллану һәм язу
6. Антоним, синоним, омонимнарны аера һәм сөйләмдә урынлы куллану.
7. Татарча-русча, русча-татарча һәм башка төр сүзлекләрдән файдалану.
8. Лексик берәмлекләрнең күчерелмә мәгънәләрен, башка сүзләр белән бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен белү.
9. Аерым сүз төркемнәренә хас грамматик формаларның татар һәм рус телләрендә тәңгәл килү-килмәвен белү: татар телендә исемнең род категориясе булмавы һәм аның лексик берәмлекләр белән бирелеше; татар телендәге исемдә тартым категориясе булуы һәм аның рус телендә бирелеше; татар телендә хикәя фигыльнең заман формаларының мәгънәви үзенчәлекләре; татар телендә фигыльнең вид категориясе булмавы, шунлыктан аның төрле формалар белән бирелеше; татар телендә сыйфатның сыйфатланмыш белән ярашмавы; бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең татар телендә сүздән соң килүе; татар сөйләмендә кисәкчәләрнең препозитив һәм постпозитив булуы; татар телендә саннарның һәм сыйфатларның исем янында төрләнмәве; микъдар саны белән янәшә килгәндә, исемнәрнең сан белән төрләнмәве.
10. Җөмләдә сүзләрне бәйләүче чараларны гамәли куллана белү.
11. Татар телендәге хикәя җөмләнең хәбәр белән тәмамлану үзенчәлеген истә тотып, сөйләм оештыру алу.
12. Татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуын белү. 13. Иярченле кушма җөмләләрнең сөйләмдә актив кулланыла торган төрләреннән файдалана алу. Синтетик иярчен җөмләләрнең һәрвакыт баш җөмлә алдыннан килү үзенчәлеген истә тотып, сөйләм оештыра алу.
14. Бер үк фикерне төрле синтаксик калыплар белән белдерә алу.
15. Язма сөйләмдә тыныш билгеләрен дөрес куюга ирешү: ия белән хәбәр арасында сызык; җөмләнең аерымланган кисәкләре, модаль сүзләр, тиңдәш кисәкләр янында, кушма җөмләдә тыныш билгеләре (өтер, ике нокта, сызык)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**

Рус мәктәбендә укучы балаларны бәйләнешле сөйләмгә өйрәтү дәвамлы һәм мөһим бурычлардан санала. Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре өчен вакыт күләме дә аерым күрсәтелә. Аны үтәү тиешле материалны өйрәнүгә бәйле рәвештә телдән һәм язмача үтәлә торган эшләр вакытында башкарыла.

Темаларны үзләштергәннән соң, **укучылар өйрәнәчәк**:

- **Лексика буенча**:“Татарстан Республикасының халыкара мөнәсәбәтләре”, “Чит илләрдәге татарлар”, “Россиядә татар телен укыту”, “Татарстан республикасының Милли китапханәсе”, “Татар матбугаты”, “Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары”, “Сынлы сәнгать”, “Асылташлар дөньясында”, “Эш кәгазьләре”, “Халыкка багышланган гомер”, “Татар әдипләре иҗатыннан” бүлекләренә караган яңа сүзләрне.

-**Грамматика буенча:** Татар сөйләмен фонетик яктан дөрес оештыруны; татар телендә сүз басымының үзенчәлекләрен һәм аерым грамматик формалардагы сүзләрдә басымны дөрес куюны;сөйләмдә иҗек чигендәге фонетик үзгәрешләрне: *кук — күге, кунак — кунагы, тап — таба, тек әле — тегәле;* хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләрне дөрес интонация белән әйтергә, кушма, тезмә, парлы һәм кыскартылма сүзләрне; антоним, синоним, омонимнарны;татарча-русча, русча-татарча һәм башка төр сүзлекләрдән файдаланырга; лексик берәмлекләрнең күчерелмә мәгънәләрен, башка сүзләр белән бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен; аерым сүз төркемнәренә хас грамматик формаларның татар һәм рус телләрендә тәңгәл килү-килмәвен белергә: татар телендә исемнең род категориясе булмавы һәм аның лексик берәмлекләр белән бирелеше; татар телендәге исемдә тартым категориясе булуы һәм аның рус телендә бирелеше; татар телендә хикәя фигыльнең заман формаларының мәгънәви үзенчәлекләре; татар телендә фигыльнең вид категориясе булмавы, шунлыктан аның төрле формалар белән бирелеше; татар телендә сыйфатның сыйфатланмыш белән ярашмавы; бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең татар телендә сүздән соң

килүе;  татар сөйләмендә кисәкчәләрнең препозитив *(иң, үтә, тома, шыр, әллә)* һәм постпозитив *(түгел, бит, инде, әле, гына/генә, кына/кенә, ук/үк)* булуы; татар телендә саннарның һәм сыйфатларның исем янында төрләнмәве *(өч малайда — у трех мальчиков; бишенче сыйныфта — в пятом классе; җиде баланың — у семи детей, матур бинада — в красивом здании);* микъдар саны белән янәшә килгәндә, исемнәрнең сан белән төрләнмәвен; җөмләдә сүзләрне  бәйләүче чараларны гамәли куллана белүне; татар телендәге хикәя җөмләнең хәбәр белән тәмамлану үзенчәлеген истә тотып, сөйләм оештыру алуны; татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуын белүне. *(Бүген безгә **кунаклар** килә. Кунаклар безгә **бүген** килә. Кунаклар бүген **безгә** килә.);* иярченле кушма җөмләләрнең сөйләмдә актив кулланыла торган төрләреннән файдалана алуны.Синтетик иярчен җөмләләрнең һәрвакыт баш җөмлә алдыннан килү үзенчәлеген истә тотып, сөйләм оештыра алуны; бер үк фикерне төрле синтаксик калыплар белән белдерә алуны; язма сөйләмдә тыныш билгеләрен дөрес куюга ирешү: ия белән хәбәр арасында сызык; җөмләнең аерымланган кисәкләре, модаль сүзләр, тиңдәш кисәкләр янында, кушма җөмләдә тыныш билгеләрен (өтер, ике нокта, сызык).
Укучылар өйрәнергә **мөмкинлек алачак:**“Татарстан Республикасының халыкара мөнәсәбәтләре”, “Чит илләрдәге татарлар”, “Россиядә татар телен укыту”, “Татарстан республикасының Милли китапханәсе”, “Татар матбугаты”, “Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары”, “Сынлы сәнгать”, “Асылташлар дөньясында”, “Эш кәгазьләре”, “Халыкка багышланган гомер”, “Татар әдипләре иҗатыннан” бүлекләренә караган өстәмә лексиканы үзләштерергә.

Шулай ук укучылар ел ахырында гади һәм кушма җөмләләрне, аларның җөмләдә дөрес кулланышын  кабатлыйлар. Теркәгечле һәм теркәгечсез кушма җөмләләрне сөйләмдә куллану күнекмәләрен, иярченле кушма җөмләләрнең сөйләмдә актив булган аналитик һәм синтетик төрләрен, аларга хас бәйләүче чараларны һәм рус теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләрен искә төшерәләр. Сөйләмнең иң зур берәмлеге текст турында белемнәрен ныгыталар**.**

Чыгарылыш сыйныф укучылары ел дәвамында фонетика ( иҗек, сүз басымы, фонетик үзгәрешләр),  әйтелеше ягыннан җөмлә төрләре , лексикология (антоним, синоним, омонимнар), лексикология ( сүзлекләр), морфология   (исемдә килеш, тартым категориясе, бәйлекләр, кисәкчәләр, теркәгечләр), синтаксис (җөмлә кисәкләре) турында булган белемнәрен ныгыталар. Шулай ук укучылар ел ахырында гади һәм кушма җөмләләрне, аларның җөмләдә дөрес кулланышын  кабатлыйлар. Теркәгечле һәм теркәгечсез кушма җөмләләрне сөйләмдә куллану күнекмәләрен, иярченле кушма җөмләләрнең сөйләмдә актив булган аналитик һәм синтетик төрләрен, аларга хас бәйләүче чараларны һәм рус теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләрен искә төшерәләр. Сөйләмнең иң зур берәмлеге текст турында белемнәрен ныгыталар**.**

## Укыту предметының эчтәлеге

### 10нчы сыйныф

1. ТатарстанРеспубликасының халыкара мөнәсәбәтләре
2. Чит илләрдәге татарлар
3. Телләр белгән- илләр белгән
4 Татарстан Республикасының Милли китапханәсе
5. Татар матбугаты
6.Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары
7. Сынлы сәнгать
8. Асылташлар дөньясында
9. Эш кәгазьләре
10. Халыкка багышланган гомер
11. Татар әдипләре иҗатыннан

### 11нче сыйныф

1. Югары белем

2. Татарстанның фәнни казанышлары
3. Һөнәр сайлау
4. Ял итү һәм спорт
5. Татар музыка сәнгате һәм фестивальләр
6. Татарстан радиосы һәм телевидениесе
7. Татарстан музейлары
8. Тарихка сәяхәт
9. Татарстанның истәлекле урыннары
10. Халыкка багышланган гомер
11. Татар әдипләре иҗатыннан

**Родная (татарская) литература**
**(рус төркемнәре)**

Татар әдәбиятын укытуның төп **максатлары:**

- матур әдәбият текстларын кабул итү, төп әдәби-тарихи мәгълүматларны белү;
- әдәби-тарихи процесс турында гомуми караш булдыру;
- гуманлык карашлары, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, татар әдәбиятына, татар халкының рухи Һәм мәдәни кыйммәтләренә ихтирам тәрбияләү;
- телдән Һәм язма сөйләм аша әдәби зәвык үстерү;
- татар классик әдәбияты, балалар әдәбияты, хәзерге татар әдәбиятының күренекле вәкилләрен атый белү, аларның әсәрләреннән өзекләрнең әчтәлеген аңлау Һәм фикер алыша белү;
- татар халкының әдәбияты, тарихы, мәдәнияте буенча мәгълүматлы булу;
- вакытлы матбугат язмаларын, мәгълумати текстларны укырга һәм аларга күзәтү ясарга, анда күтәрелгән мәсьәләләргә карата уз мөнәсәбәтеңне дәлилләп белдерергә күнектерү;
- татар сәнгатенең куренекле вәкилләре турында хәбәрдар булу.

**Укыту предметының эчтәлеге**
**10нчы сыйныф**

Татар әдәбиятын өйрәнү өчен эчтәлек сайлау әдәбият белемендә кабул ителгән эстетик һәм әдәби принципларга бәйле.

Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре: легендалар, риваятьләр.

Сүз сәнгатенең барлык жанрларына да кагылган күренекле татар әдипләренең әсәрләреннән (хикәя,шигырь,поэма,повесть, роман, ) өзекләр:

**Дәрдемәнд**. “Каләмгә Хитаб”(Каләмгә эндәшү), “Шагыйрьгә”, “Кояшның нурлары”; **С.Рәмиев.** “Авыл”, “Уку”, “Сызыла күңел”;**Г.Тукай.** “Мәхәббәт”,”Шагыйрь”, “Хөррият хакында”; **Г.Исхакый.**“Кәләпүшче кыз”, “Остазбикә”**; К.Тинчурин.** “Сүнгән йолдызлар”; **М.Хәбибуллин.** “Кубрат хан”; А.**Гыйләҗев**.”Ягез бер дога”; **И.Юзеев.** “Гашыйклар тавы”; **Р.Харис.**”Сабантуй”, “Чулпы”,”Ак сөлге”; **Р.Фәйзуллин.** “Яшь чак”, “Туган ягым”,”Яран гөл”, **Зөлфәт.** “Колын”, “Тылсым”, “Дүрт җыр”;**З.Хәким.** “Кишер басуы”; **Р.Зәйдулла.** “Төнге әкият”, “Кизләү”.

Татар халкының сәнгате, тарихы, мәгърифәт үсешен чагылдырган мәгълүмәти материаллар. Вакытлы матбугат язмалары. Прагматик һәм эпистоляр жанр текстлары.

**Сөйләмнең предмет эчтәлеге**

ТатарстанРеспубликасының халыкара мөнәсәбәтләре
2. Чит илләрдәге татарлар
3. Телләр белгән- илләр белгән
4 Татарстан Республикасының Милли китапханәсе
5. Татар матбугаты
6.Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары
7. Сынлы сәнгать

8. Асылташлар дөньясында
9. Эш кәгазьләре
10. Халыкка багышланган гомер
11. Татар әдипләре иҗатыннан

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**

Темаларны үзләштергәннән соң, **укучылар өйрәнәчәк**:

- **Лексика буенча**:“Татарстан Республикасының халыкара мөнәсәбәтләре”, “Чит илләрдәге татарлар”, “Россиядә татар телен укыту”, “Татарстан республикасының Милли китапханәсе”, “Татар матбугаты”, “Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары”, “Сынлы сәнгать”, “Асылташлар дөньясында”, “Эш кәгазьләре”, “Халыкка багышланган гомер”, “Татар әдипләре иҗатыннан” бүлекләренә караган яңа сүзләрне.
- Татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен: легендалар, риваятьләр.
- Төрле әдәби жанрлардагы әсәрләрне (хикәя,шигырь, поэма,повесть, роман), әхлакый проблеманы үз эченә алган өзекләрне.

Татар әдипләренең әсәрләрен: **Дәрдемәнд**. “Каләмгә Хитаб”(Каләмгә эндәшү), “Шагыйрьгә”, “Кояшның нурлары”; **С.Рәмиев.** “Авыл”, “Уку”, “Сызыла күңел”; **Г.Тукай.** “Мәхәббәт”,”Шагыйрь”, “Хөррият хакында”; **Г.Исхакый.** “Кәләпүшче кыз”, “Остазбикә**”; К.Тинчурин.** “Сүнгән йолдызлар”; **М.Хәбибуллин.** “Кубрат хан”; А.**Гыйләҗев**.”Ягез бер дога”; **И.Юзеев.** “Гашыйклар тавы”; **Р.Харис.**”Сабантуй”, “Чулпы”,”Ак сөлге”; **Р.Фәйзуллин.** “Яшь чак”, “Туган ягым”,”Яран гөл”, **Зөлфәт.** “Колын”, “Тылсым”, “Дүрт җыр”; **З.Хәким.** “Кишер басуы”; **Р.Зәйдулла.** “Төнге әкият”, “Кизләү”.

Татар халкының сәнгате, тарихы, мәгърифәт үсешен чагылдырган мәгълүмәти материаллар. Вакытлы матбугат язмалары. Прагматик һәм эпистоляр жанр текстлары.

Укучылар өйрәнергә **мөмкинлек алачак:**“Татарстан Республикасының халыкара мөнәсәбәтләре”, “Чит илләрдәге татарлар”, “Телләр белгән- илләр белгән”, “Татарстан республикасының Милли китапханәсе”, “Татар матбугаты”, “Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары”, “Сынлы сәнгать”, “Асылташлар дөньясында”, “Эш кәгазьләре”, “Халыкка багышланган гомер”, “Татар әдипләре иҗатыннан” бүлекләренә караган өстәмә лексиканы үзләштерергә.

**11нче сыйныф**

Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре: дастаннар.

Сүз сәнгатенең барлык жанрларына да кагылган күренекле татар әдипләре әсәрләреннән ( хикәя, шигырь, повесть, роман)өзекләр;

Татар әдипләренең әсәрләре:

Һ. Такташ. «Мәхәббәт тәүбәсе»; М. Җәлил «Хуш, акыллым», «Кошчык»; «Бүреләр»; Г.Кутуй «Тапшырылмаган хатлар»; Ф.Әмирхан «Шәфигулла агай»; М.Әмир «Агыйдел»; Г.Әпсәләмов. «Алтын йолдыз»; Х.Туфан «Кайсыгызның кулы җылы», «Илдә ниләр бар икән?», «Луиза»; М.Мәһдиев «Бәхилләшү»; Ф.Хөсни «Утызынчы ел»; Т.Миңнуллин «Әлдермештән Әлмәндәр»; М. Хәсәнов «Язгы аҗаган»; Р.Вәлиев «Кыңгырау»,«Сөембикә»;

Р.Гаташ. «Ирләр булыйк», «Укытучы»; Р.Зәйдулла «Битлек»; И. Юзеев «Өчәү чыктык ерак юлга»,«Мәңгелек белән очрашу»,«Очты дөнья читлегеннән».

Татар халкының сәнгате, тарихы, мәгърифәт үсешен чагылдырган мәгълүмати материаллар.

Вакытлы матбугат язмалары.

Прагматик һәм эпистоляр жанр текстлары..

**Сөйләмнең предмет эчтәлеге**

1. Югары белем
2. Татарстанның фәнни казанышлары
3. Һөнәр сайлау
4. Ял итү һәм спорт
5. Татар музыка сәнгате һәм фестивальләр

6. Татарстан радиосы һәм телевидениесе
7. Татарстан музейлары
8. Тарихка сәяхәт
9. Татарстанның истәлекле урыннары
10. Халыкка багышланган гомер
11. Татар әдипләре иҗатыннан